ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.05.2023 Олы Кайбыч авылы № 186

Кайбыч муниипаль районы Башкарма комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2019 елның 25 февралендәге 65 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2019 елның 25 февралендәге 65 номерлы Башкарма комитет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырыла торган җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге.»;

1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар тарафыннан Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр.».

1.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат исемлеге.».

1.3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр» кушымтасының аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм аларга буйсынучы оешмалар тарафыннан Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе Д.Ә. Бәдретдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров